КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 декабрь г.Казань № 1328

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1046 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1046 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 3 май, 259 нчы; 2019 ел, 27 февраль, 128 нче; 2019 ел, 27 июль, 626 нчы, 2019 ел, 30 декабрь, 1236 нчы, 2021 ел, 21 май, 360 нчы, 2022 ел, 10 июнь, 545 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грант турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан

Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.1 пунктның дүртенче абзацында «30 нчы» сүзләрен «10 нчы» сүзләренә алмаштырырга;

2.7 пунктның өченче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «башкарма органнар» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның алтынчы абзацында «грант бирү нәтиҗәсе күрсәткече» сүзләрен «грант бирү төгәлләнә торган төгәл дата һәм аны бирү нәтиҗәсенең соңгы күрсәткече (йомгакларның төгәл микъдари тасвирнамәсе)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин